# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2024 ел, 09 апрель № 1

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Алат спиртзаводы авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә,

“Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегенең Алан-Бәксәр авылында үткән гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча 2023 елның 9 ноябрендәге 1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертүгә Сез ризамы:

“Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегенең Алат спиртзаводы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче бәлигъ яшьтәге һәр кешедән 2024 елда 700 (җиде йөз) сум күләмендә узара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне:

- Алат спиртзаводы авылында контейнер мәйданчыклары төзү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә Сез ризамы?”

Алда әйтеп үтелгән эш төренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

“- каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү (Алат спиртзаводы авылында контейнер мәйданчыклары төзү, контейнерлар сатып алу (материаллар сатып алу, хезмәтләр өчен түләү) Сез ризамы?

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

соравы буенча 2024 елның 9 апррелендә 09 сәгать 00 минутта уздырылган гражданнар җыенының нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 75 (Җитмеш биш) граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 40 кеше, бу 53,3 % тәшкил итә;

тавыш бирү нәтиҗәләре буенча, җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 40 (Кырык) кеше тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенның 0 (ноль) катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегенең Алат спиртзаводы авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. "Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегенең Алан-Бәксәр авылында үткән гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча 2023 елның 9 ноябрендәге 1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертүгә Сез ризамы:

"Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегенең Алат спиртзаводы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче бәлигъ яшьтәге һәр кешедән 2024 елда 700 (җиде йөз) сум күләмендә узара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне:

- Алат спиртзаводы авылында контейнер мәйданчыклары төзү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә Сез ризамы?"

Алда әйтеп үтелгән эш төренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

"- каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү (Алат спиртзаводы авылында контейнер мәйданчыклары төзү, контейнерлар сатып алу (материаллар сатып алу, хезмәтләр өчен түләү) Сез ризамы?

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

соравы буенча уңай карар кабул ителде дип танырга.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында»: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Алан-Бәксәр авыл җирлеге башлыгы: З.Р.Гарифуллина